РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2022 Олы Кайбыч ав. № 25

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2008 елның 23 маендагы 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы тора.
3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2022 елның 20 мае 10 сәг 00 минут;
- үткәрү урыны: Кайбыч районы, Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 йорт адресы буенча урнашкан Ульянково авыл җирлеге административ бинасы:
- 2022 елның 20 маена кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адреслар:

Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар ур., 7 йорт, Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

Кайбыч районы, Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 йорт Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге башкарма комитеты

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль

районы Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проектын карау буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык А.И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының
2022 елның 18.04.2022
25 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проектын карау буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:*<br>Макаров А.Н. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре*:<br>Гайнуллина Ю.В. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:*<br>Әхмәтов Ф.Ш.<br><br>Макарова О.Д.<br><br>Сундурова Ф.А. | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары (килешү буенча)<br><br>Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча)<br><br>Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |